ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

04.03.2019 с. Верхний Услон 204

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
«Мәмәтхуҗа балалар бакчасы»
Муниципаль Бюджет Мәктәпкәчә
белем бирү учреждениесен
бетерү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында» 08.08.2001 ел, № 129-ФЗ Федераль закон, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 12.01.1996 ел, №7-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, "Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, бюджет акчаларын тотуны оптимальләштерү, матди-техник ресурслардан нәтиҗәле файдалану һәм белем бирү учреждениесе белән идарә итүнең оптималь системасын формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 422589, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Школьная урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Мәмәтхуҗа балалар бакчасы» Муниципаль Бюджет Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен 2019 елның 1 сентябренә кадәр бетерергә.
2. “Мәмәтхуҗа балалар бакчасы” мөдире Н.И. Цветковага гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә бетерү буенча чаралар үтәлешен тәэмин итәргә:
- юридик затның юридик затны закон белән билгеләнгән тәртиптә бетерү турында дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органга әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә бетерү турында язмача хәбәр итәргә;
- тиешле чаралар үткәрүгә кадәр ике ай кала кыскартылу турында балалар бакчасы хезмәткәрләренә хәбәр әзерләргә һәм тапшырырга;
- штат кыскартылу турында язма рәвештә беренчел профсоюз оешмасының сайлау органына, тиешле чаралар үткәрүгә ике айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә;
- эшкә урнашуга мохтаҗ булган эштән китүчеләр турында мәшгульлек үзәгенә хәбәр итәргә;
- “Мәмәтхуҗа балалар бакчасы”н юк итү турында «Дәүләт теркәве хәбәрләре»ндә, гариза бирү тәртибе һәм сроклары, аның кредиторлары таләпләре күрсәтелгән белдерүләр бастыруны тәэмин итәргә;
- “Мәмәтхуҗа балалар бакчасы” өчен җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын туктату һәм бинага һәм мөлкәткә оператив идарә итү хокукын туктату турында гариза белән Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

- МБДОУ “Мәмәтхуҗа балалар бакчасының” архив документларын Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәгариф бүлеге“ МКУ саклауга тапшырырга;
- “Мәмәтхуҗа балалар бакчасы”н законда билгеләнгән тәртиптә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру буенча чаралар күрергә.

3. «Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына, кредиторлар белән исәп-хисап тәмамланганнан соң, ликвидация балансын төзергә һәм расларга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Әзерләде һәм бастырды
Ю.С. Лыкина
5 нөсхәдә